**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

КАРАР
№ 176

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
“05” 03 2022 ел

Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 26 гыйнварында кабул ителгән «Спас муниципаль районы территорияләренә муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын беркетү турында»гы 71нче карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9, 67 статьясы, «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча укырга кабул итү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 номерлы боерыгы нигезендә гражданнарның һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез белем алуга конституциячел хокукларын үтәү максатларында Спас муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы территорияләренә муниципаль бюджет белем бирү оешмаларын беркетү турында»2022 елның 26 гыйнварындагы 71 номерлы карарына теркәлгән кушымтага үзгәреш кертү турында:

1.1. № 4, № 6 пунктка кушымталарны «территория» баганасында Кызыл Бистә авылын өстәргә.

2. Муниципаль бюджет белем бирү оешмалары җитәкчеләренә әлеге карар нигезендә мәктәпкәчә гомуми, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укырга кабул итәргә.

3. Мәгълүмат стендларында һәм белем бирү оешмаларының рәсми сайтларында әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтларда басылганнан соң 10 календарь көн эчендә урнаштыру.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В.А. Осокин